# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 27 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында» 2010 елның 22 ноябрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 11; 2011, № 10 (I өлеш) «сыра эчемлекләрен» сүзләреннән соң «, сидрны, пуарены, әче балны» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2013 елның 20 мае
№ 40-ТРЗ